РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН СОВЕТ
СТАРОСТУДЕНЕЦКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ СУЫКСУ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

30 июль 2026 ел № 1-19

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Иске Суыксу авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Иске Суыксу авыл җирлеге башкарма комитеты турында нигезләмә хакында» 2011 елның 22 декабрендәге 1-17 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

2025 елның 20 мартындагы «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 33-ФЗ номерлы Федераль законның 37 статьясы, «Дәүләт (муниципаль) учреждениеләренең хокукый хәлен камилләштерүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 83-ФЗ номерлы Федераль закон, «Муниципаль идарәне һәм муниципаль учреждениеләрнең хокукый хәлен камилләштерү концепциясе турында» Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр Советы Президиумының 2010 елның 04 июнендәге ПР-11-2 номерлы карары, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы законының 25 статьясы,(25.04.2026 ел редакциясе), «Иске Суыксу авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставының 46-53 статьялары нигезендә Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Иске Суыксу авыл җирлеге Советы карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Иске Суыксу авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Иске Суыксу авыл җирлеге башкарма комитеты турында Нигезләмә хакында» 2011 елның 22 декабрендәге 1-17 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 3 өлешнең 1 пункты

1. Җирлекнең башкарма комитетына муниципаль берәмлек уставы белән халыкның тормыш эшчәнлеген турыдан-туры тәэмин итү мәсьәләләрен хәл итү вәкаләтләре һәм федераль законнар һәм Россия Федерациясе субъектлары законнары белән җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру вәкаләтләре бирелә.

2. Әлеге карар басылып чыккан вакыттан законлы көченә керә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырылырга тиеш (https://pravo.tatarstan.ru/), шулай ук Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында (http://buinsk.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы Буа муниципаль
районының Иске Суыксу авыл җирлеге башлыгы М.М. Дәүләтшин